ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.09.2023 с.Старое Дрожжаное № 364

Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага, даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 492-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палаталарына муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 13 сентябрендәге 398 номерлы карары (17.10.2022 № 533 редакциясендә) белән расланган Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага, даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымтаның **16 пунктында, дүртенче баганага** «әлеге күчемсез милек объектлары» сүзләрен «дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге биналар, арендага бирелгән» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов